РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«21» февраль 2025 ел Олы Кайбыч ав. № 309

Кайбыч муниципаль районы Советының 2021 елның 08 декабрендәге 74 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 08 декабрендәге 74 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.4. пунктын излтүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 60 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү турында яисә зыян (зарар) китерү куркынычы турында мәгълүматлар булу;

2) контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру планына кертелгән контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру срокларын билгеләү;

3) вәкаләтләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган Россия Федерациясе Президенты йөкләмәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең конкрет контрольдә тотыла торган затларга карата контроль (күзәтчелек) чараларын уздыру турында йөкләмәсе (шул исәптән федераль дәүләт контроле (күзәтчелек) төрләренә карата);

4) законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча үтәү кысаларында контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында прокурор таләбе;

5) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның

95 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән очракларда мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында контроль (күзәтчелек) органы карарын үтәү срогы тәмамлану;

6) әгәр федераль законда контроль (күзәтчелек) чаралары тикшерү программасы нигезендә уздырыла, дип билгеләнгән булса тикшерүләр программасында күрсәтелгән вакыйга вакыты керү;

7) мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга контроль объектының туры килүен яисә контроль объектының мондый параметрлардан баш тартуын ачыклау;

8) әгәр мондый хәбәрнамәне тапшыру мәҗбүри булган очракта яисә «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешенең 6 - 9.1, 11, 12, 14 - 17, 19 - 21, 24 - 31, 34 - 36, 39, 40, 42 - 55 һәм 59 пунктларында күрсәтелгән эшчәнлек төрләре өчен каралган лицензиясе булмаса, яисә күрсәтелгән мәгълүмат системасында теркәлү өчен кирәкле белешмәләрне идентификацияләү чаралары белән мәҗбүри тамгаланырга тиешле товарлар әйләнешен мониторинглауның дәүләт мәгълүмат системасына тапшырмыйча контроль (күзәтчелек) чарасын тикшерү объекты урнашкан урын буенча прокуратура органының егерме дүрт сәгать дәвамында уздыру турында хәбәр итеп, мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булган очракларда, Башкарма комитетта «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр бирмичә эшчәнлек башкару турында белешмәләр булу;

9) контрольдә тотыла торган затның мәҗбүри профилактик визит уздырудан читләшүе.».

1.2. 3.20. пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) контрольдә тотыла торган затка контроль (күзәтчелек) чарасы актын рәсмиләштергәннән соң, аларны бетерүнең тиешле срокларын күрсәтеп, мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында, шулай ук федераль законда контроль рәвеше турында каралган башка чараларны күрсәтү хакында күрсәтмә бирергә;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин